ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№ 70 от «19» 02 2021 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш
муниципаль районының берләштерелгән
бюджетына салымнар буенча бурычларны
киметү буенча чараларны гамәлгә ашыру
буенча ведомствоара комиссия ( штаб) турындагы
Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының берләштерелгән бюджетына салымнар буенча бурычларны киметү буенча чараларны гамәлгә ашыру максатында, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты к а р а р б и р ә:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 1 августындагы 929 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының берләштерелгән бюджетына салымнар буенча бурычларны киметү буенча чараларны гамәлгә ашыру буенча ведомствоара комиссия ( штаб) турындагы Нигезләмәгә (алга таба – Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 5 пунктын, 5.1-5.3 пунктларын төшереп калдырып, түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Комиссия рәисе Комиссия белән гомуми җитәкчелек итә, комиссиянең эш юнәлешләрен һәм планын билгели, раслый, комиссия утырышлары беркетмәләренә кул куя, беркетмәләрдән өземтәләр төзи, комиссия тарафыннан кабул ителгән беркетмәләрнең үтәлешен контрольдә тота. Комиссия рәисе вакытлыча булмаганда, аның вазыйфаларын урынбасарларының берсе башкара.

Комиссия секретаре Комиссия эшчәнлеген оештыру ягыннан тәэмин итә, комиссиянең эш башкаруын алып бара, комиссия әгъзаларын һәм аның утырышына чакырылган затларны көн тәртибе, үткәрү датасы, урыны турында хәбәр итә, фикер алышуга тиешле документлар проектларын һәм башка материалларны җибәрә, Комиссия утырышларын әзерләүне оештыра.

1.2. Нигезләмәнең 6 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Комиссия утырышы, әгәр анда аның әгъзаларының яртысыннан артыгы катнашса, хокуклы дип санала. Комиссия карары утырышта катнашучыларның

0000010774

күпчелек тавышы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булганда утырышта рәислек итүче тавышы хәлиткеч булып тора. Карарны беркетүче комиссия утырышы беркетмәсе комиссия секретаре тарафыннан төзелә һәм комиссия утырышы көнендә комиссия рәисе һәм Секретаре тарафыннан имзалана. Комиссия утырышлары беркетмәләренең күчермәләре комиссия утырышы уздырылганнан соң 3 эш көне эчендә аның әгъзаларына җибәрелә.

2. Әлеге карарны Мамадыш муниципаль районының рәсми mamadysh.tatarstan.ru сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары В.И.Никитинга йөкләргә.

Җитәкче И.М. Дәрҗеманов